ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«03» апрель 2024 ел Борды авылы № 8

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге составына керүче Бордыбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Бордыбаш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Бордыбаш авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Борды авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советының 2019 елның 07 ноябрендәге 51/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге составына керүче Бордыбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Бордыбаш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреленэ 13.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге составына керүче Бордыбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау»;

«-торак пункт территориясен төзекләндерү»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Борды авылында гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау»;

«-торак пункт территориясен төзекләндерү».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Борды авыл җирлеге, Бордыбаш авылы, Узэк ур., 83 йорт (авыл клубы бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Борды авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Абдульманова